РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 2 » февраля 2021 ел г. Альметьевск № 112

Эшләмәүче I һәм II төркем
инвалидларга социаль ярдәм
чаралары күрсәтү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына таянып, хокукый мониторинг тәртибендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Өстәмә керемнәр исәбенә район бюджетын үтәү процессында эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә бала караган һәм тәрбияләгән өчен акчалата компенсация рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чараларын күрсәтергә.

«Әлмәт муниципаль районының социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмнәрдә куллану юлы белән һәм социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында билгеләнгән форматлар нигезендә файдалану юлы белән социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларына социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында мәгълүмат социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмнәрдә куллану юлы белән һәм социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасында билгеләнгән форматлар нигезендә алынырга мөмкин.

2. Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында » 2011 елның 26 апрелендәге 1653 номерлы;

«Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 26 апрелендәге 1653 номерлы карарының гамәлдә булу срогын үзгәртү һәм озайту хакында» 2012 елның 21 мартындагы 826 номерлы карары;

Зак. № 305-2000

«Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 26 апрелендәге 1653 номерлы карарының гамәлдә булу срогын үзгәртү һәм озайту турында» 2013 елның 19 апрелендәге 1676 номерлы карары;

«Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 26 апрелендәге 1653 номерлы карарының гамәлдә булу срогын озайту хакында» 2014 елның 21 февралендәге 586 номерлы карары;

«Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 26 апрелендәге 1653 номерлы карарының гамәлдә булу срогын озайту хакында» 2015 елның 06 июлендәге 725 номерлы карары;

«Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 26 апрелендәге 1653 номерлы карарының гамәлдә булу срогын озайту хакында» 2017 елның 25 августындагы 1409 номерлы карары».

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Шәйдуллина З.Р.) эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга район бюджетын үтәү барышында өстәмә алынган керемнәр исәбеннән акчалар бүлеп бирүне күздә тотарга тәкъдим итәргә.

5. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«_2_» февраль 2021 ел №112
карары белән расланган
1 нче кушымта

Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турындагы нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге нигезләмә Әлмәт муниципаль районында яшәүче эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларына муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә бала караган һәм тәрбияләгән өчен акчалата компенсация рәвешендә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын бирү тәртибен һәм шартларын регламентлаштыра.

## 2. Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларына социаль ярдәм чаралары

Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларына социаль ярдәм күрсәтү максатларында ата-ана түләвенең факттагы исәпләнгән күләме арасында компенсация түләүләре бирү, муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен, «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы һәм Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 3662 номерлы карарлары белән каралган ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү күздә тотыла.

## 3. Социаль ярдәм чараларын күрсәтү шартлары һәм тәртибе

3.1. Компенсация түләүләре кварталга 1 тапкыр башкарыла.

3.2. «Әлмәт муниципаль районының социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә компенсация алу өчен инвалидлар ел саен 15 марттан да соңга калмыйча түбәндәге документлар тапшыралар:

- гариза;
- мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ күчермәсе;
- балалар туу турында таныклык күчермәсе;
- хезмәт кенәгәсенең күчермәсе;
- түләүләрне күчерү өчен банк счеты.

3.3. «Әлмәт муниципаль районының социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе:

а) компенсацияләү суммасын исәпли, исәпләүләр реестрын төзи һәм финанслау өчен Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гариза бирә;

б) квартал саен хисап кварталыннан соң килүче санның 15 енә кадәр, мөрәҗәгать итүчеләрнең исәп-хисап счетларына исәпләнгән компенсация суммасын санап чыга.

3.4. Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсе квартал саен, хисап аеннан соң киләсе айның 10 нчы числосына кадәр, кәгазь чыганакта «Әлмәт муниципаль районының социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенә исәп-хисап ясый.

3.5. Республика матди ярдәм үзәгенең 8 нче филиалы квартал саен, хисап аеннан соң киләсе айның 10 нчы числосына кадәр, кәгазь чыганакта «Әлмәт муниципаль районының социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы һәм Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 3662 номерлы карарлары белән каралган ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация суммасын бирә.

3.6. Социаль ярдәм чараларын алучыларның салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш.

## 4. Чыгымнарны финанслау

Эшләмәүче I һәм II төркем инвалидларга социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанслау район бюджетын үтәү процессында өстәмә алынган керемнәр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева